ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.04.2023 п.г.т. Алексеевское № 120

**Алексеевск муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.09.2014 ел, № 635 «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контракт нигезендә күрсәтү хакында» турында карарын тормышка ашыру максатларында

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Расларга:

2.1. Алексеевск муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә (1 нче кушымта).

2.2. Алексеевск муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составы (2 нче кушымта).

3. Көчен югалткан дип танырга:

3.1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 25.03.2011 ел, № 184 «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында» карары

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
07.04.2023 ел, № 120
карарына 1 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районындагы социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘ

1.1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.09.2014 ел, №635 «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме,шул исәптән социаль контракт нигезендә күрсәтү турында» карарына ярашлы рәвештә төзелде.

1.2. Ведомствоара комиссия Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесе карары белән төзелә.

1.3. Ведомствоара комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) нигезендә эш итә.

## 2. ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯНЕҢ ФУНКЦИЯЛӘРЕ ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

2.1. Ведомствоара комиссия Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау бүлеге (алга таба – социаль яклау бүлеге) тарафыннан социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турындагы гаризаны һәм документларны, гаиләне (ялгыз яшәүче гражданны) социаль адаптацияләү программасын, бизнес планны карый.

2.2. Гаиләне (ялгыз яшәүче гражданны) социаль адаптацияләү программасы һәм бизнес-план ведомствоара комиссия рәисе тарафыннан раслана һәм социаль яклау бүлеге тарафыннан тәкъдим ителгәннән соң җиде көннән дә соңга калмыйча аның әгъзалары тарафыннан имзалана.

## 3.ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯНЕҢ ХОКУКЛАРЫ

Ведомствоара комиссия хокуклы:

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнарыннан, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының башка җирле үзидарә органнарыннан, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль учреждениеләреннән ведомствоара комиссия эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмат (материаллар) алырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында федераль башкарма хакимиятнең территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, шулай ук оешмалардан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән ведомствоара комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәгълүмат сорарга;

килешү буенча Татарстан Республикасы ведомствоара комиссиясе, Татарстан Республикасында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук район территориясендә урнашкан предприятие, учреждение һәм оешма вәкилләрен эшкә җәлеп итәргә.

## 4. ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯНЕҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

4.1. Ведомствоара комиссия утырышлары кирәк булганда үткәрелә.

4.2. Ведомствоара комиссия эшенә аның рәисе җитәкчелек итә.

4.3.Комиссия утырышы, әгәр анда ведомствоара комиссия әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы. Ведомствоара комиссия әгъзалары аның утырышларында алмашуга хокукысыз катнашалар. Әгәр ведомствоара комиссия әгъзасы утырышта катнаша алмаса, ул каралган мәсьәләләр буенча үз фикерен алдан ук язма формада тәкъдим итәргә хокуклы.

4.4. Ведомствоара комиссия карары ведомствоара комиссия әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта ведомствоара комиссия рәисе тавышы хәл итүче булып тора. Ведомствоара комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа рәис һәм секретарь кул куя.

4.5.Ведомствоара комиссия секретаре ведомствоара комиссия утырышы беркетмәсен әзерли.

4.6. Ведомствоара комиссия карарын гариза бирүче закон нигезендә шикаять итә ала.

4.7. Ведомствоара комиссия социаль адаптация программасын һәм гариза бирүченең бизнес-планын килештерә һәм раслый.

4.8. Ведомствоара комиссия гариза бирүче булмаганда эш материалларын карау турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле.

4.9. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати тәэмин итүне социаль яклау бүлеге (килешү буенча) башкара.

**Башкарма комитетның**
**Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
07.04.2023 ел, № 120
карарына 2 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Язынин Р.С. | Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары, комиссия рәисе |
| Хәмзина Е.А. | Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Никитина Я.В. | «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» ДБУның гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлеге мөдире, Комиссия секретаре (килештерү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Солдатова М.А. | Алексеевск муниципаль районында ХМ һәм СЯМ ның социаль яклау бүлеге башлыгы (килештерү буенча) |
| Семина Н.А. | «Алексеевск муниципаль районында халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» ДБУ директоры (килештерү буенча) |
| Тимонина Н.Ю. | «Алексеевск муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килештерү буенча) |
| Кирюхина Л.Н. | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесенең урынбасары |
| Куприянова Т.В. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |
| Мусин Г.К. | Алексеевск муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе (килештерү буенча). |

**Башкарма комитетның**
**Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**